Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР № XLIV-2

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 14 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законга, «РФ субъектларының иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»2016 елның 23 июнендәге 183-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында » 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 20 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советы турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы Р.Р. Ислямов

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советы турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Нигезләмәне хокукый җайга салу предметы

1.1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законга, «РФ субъектларының иҗтимагый палаталарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»2016 елның 23 июнендәге 183-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында » 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 20 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры киререп эшләнде (алга таба – муниципаль берәмлек), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советының (алга таба - Иҗтимагый совет) хокукый статусын, аның структурасын һәм составын, Иҗтимагый советны төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен билгели.

## 2. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең хокукый нигезе

2.1. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) указлары һәм күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль берәмлек уставына һәм муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 3. Иҗтимагый советның хокукый статусы, максатлары һәм бурычлары

3.1. Иҗтимагый совет муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү максатыннан, шулай ук «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда, муниципаль берәмлекнең муниципаль норматив хокукый актларында каралган тәртиптә һәм рәвешләрдә муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатларында төзелгән даими эшләүче киңәшмә-консультатив коллегиаль орган булып тора.

3.2. Иҗтимагый совет муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба – гражданнар) һәм муниципаль берәмлек территориясендә эшчәнлек алып баручы һөнәри һәм социаль төркемнәрнең (алга

таба – коммерцияле булмаган оешмалар) хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәкъдим итү һәм яклау өчен оештырылган коммерцияле булмаган оешмаларның муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында формалаштырыла (төзелә).

3.3. Иҗтимагый совет муниципаль берәмлекнең икътисади һәм социаль үсешенең, гражданнарның һәм коммерцияле булмаган оешмаларның хокукларын һәм ирекләрен яклауның иң мөһим мәсьәләләрен хәл итү өчен гражданнарның, коммерцияле булмаган оешмаларның иҗтимагый әһәмиятле мәнфәгатьләрен ачыклау һәм килештерүне тәэмин итәргә тиеш түбәндәге юллар белән:

1) гражданнарның һәм коммерцияле булмаган оешмаларның муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

2) гражданнарның иҗтимагый әһәмиятле мәнфәгатьләрен исәпкә алу, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше дәүләт программаларын булдырганда һәм тормышка ашырганда аларның хокукларын һәм ирекләрен яклау;

3) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, коммерцияле булмаган оешмаларның һәм башка оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итү;

4) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 20 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль берәмлекнең һәм муниципаль оешмаларның җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

5) муниципаль берәмлекнең икътисадый һәм социаль үсешенең аеруча мөһим мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр әзерләү;

6) гражданнарны һәм коммерциягә карамаган оешмаларны муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше дәүләт программаларын булдыруга һәм гамәлгә ашыруга, яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләүгә, милләтара һәм диннәр арасындагы тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга җәлеп итү;

7) эшчәнлекләренең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә иҗтимагый бәя бирү.

3.4. Иҗтимагый совет җәмәгать башлангычларында эшли һәм юридик зат хокукларына ия түгел.

3.5. «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212–ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 1 өлеше 3 пунктына ярашлы рәвештә, муниципаль берәмлекнең Иҗтимагый советы җәмәгать контроле субъекты булып тора.

3.6. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим (киңәш) итү характерында.

## 4. Иҗтимагый совет эшчәнлеге принциплары

4.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп принциплары булып торалар:

1) кеше һәм гражданның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өстенлеге;

2) Иҗтимагый совет эшчәнлегенең законлылыгы;

3) Иҗтимагый советның мөстәкыйльлеге һәм аның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә

органнарыннан, дәүләт һәм муниципаль оешмалардан, федераль законнарга ярашлы рәвештә аерым җәмәгать вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка органнардан һәм оешмалардан бәйсезлеге;

4) Иҗтимагый совет эшчәнлеген гамәлгә ашыруның ачыклыгы һәм аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелек фикер алышуы.

## 5. Иҗтимагый совет әгъзаларының этика кодексы

5.1. Иҗтимагый совет президиумы Иҗтимагый совет әгъзаларының этика кодексын (алга таба этика кодексы) эшли һәм Иҗтимагый советка раслау өчен тәкъдим итә. Этика кодексында каралган таләпләрне үтәү Иҗтимагый совет әгъзалары өчен мәҗбүри булып тора.

## 6. Иҗтимагый совет Регламенты

6.1. Беренче составның Иҗтимагый советы Иҗтимагый совет регламентын Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән санының күпчелек тавышлары белән раслый.

6.2. Иҗтимагый Совет Регламенты белән билгеләнә (тәгаенләнә):

1) Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саны һәм аның эшчәнлегендә катнашу тәртибе;

2) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан Иҗтимагый совет әгъзаларының калган өчтән бер өлешен раслау тәртибе;

3) Иҗтимагый советның пленар утырышларын үткәрү вакыты һәм тәртибе;

4) Иҗтимагый советның составы, вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

5) Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасарының вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

6) Иҗтимагый совет Президиумын, Иҗтимагый совет комиссияләрен һәм эшче төркемнәрен формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибе, шулай ук аларның җитәкчеләрен сайлау һәм вәкаләтләре тәртибе;

7) әлеге типовой (үрнәк) нигезләмәгә ярашлы рәвештә Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләрен туктату һәм туктатып тору тәртибе;

8) Иҗтимагый совет карарларын кабул итү формалары һәм тәртибе;

9) Иҗтимагый совет эшенә җәмәгатьчелек экспертларын, иҗтимагый берләшмәләрне, аның составына кермәгән башка коммерцияле булмаган оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм аларның Иҗтимагый совет белән үзара эш итү рәвешләре;

10) гомумроссия һәм республика иҗтимагый берләшмәләре, муниципаль берәмлек территориясендә эшләүче башка коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләрен Иҗтимагый совет әгъзаларына сайлап алу процедуралары;

11) Иҗтимагый совет тарафыннан чараларны әзерләү һәм үткәрү тәртибе;

12) Иҗтимагый советның үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисабын әзерләү тәртибе һәм вакыты, халык алдында хисап тапшыру;

13) әлеге типовой нигезләмәгә ярашлы рәвештә Иҗтимагый советның эчке оештыру һәм эшчәнлеге тәртибенең башка мәсьәләләре.

## 7. Иҗтимагый совет составы

7.1. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә формалаштырыла (төзелә).

7.2. Иҗтимагый совет кандидатларының өчтән бер өлеше муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан раслана.

7.3. Иҗтимагый совет кандидатлары составының өчтән бер өлеше муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы) тарафыннан раслана.

7.4. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан расланган Иҗтимагый совет әгъзалары һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы)тарафыннан расланган Иҗтимагый совет әгъзалары гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә теркәлгән һәм муниципаль берәмлек территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы җирле иҗтимагый һәм башка коммерцияле булмаган оешмалар (бер җәмәгать оешмасыннан бер вәкил) тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан Иҗтимагый совет әгъзаларының калган өчтән бер өлеше составын билгелиләр.

7.5. Бер үк вакытта муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы) тарафыннан гражданнарның бер үк кандидатураларын Иҗтимагый совет составына кертүне килештерү һәм булдырмау максатыннан, муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы) тиешле исемлекләр расланганчы үзара консультацияләр үткәрә.

7.6. Иҗтимагый совет составына гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешма, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма вәкилләре дә керә ала. Шул ук вакытта аларның Иҗтимагый совет алдында куелган мәсьәләләрне тикшерү өчен зарури булган һөнәри сыйфатлары, шул исәптән тиешле белем, бу өлкәдә эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

7.7. Иҗтимагый совет составына керә ала: элек Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары, муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфалары һәм вазыйфаларын биләгән затлар, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән бер өлешеннән артмаган санда.

7.8. Иҗтимагый совет составы ул расланган көннән алып 7 көн дәвамында муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук гаммәви мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

## 8. Иҗтимагый советны формалаштыру (төзү) тәртибе һәм вәкаләтләре вакыты

8.1. Иҗтимагый совет унсигез яшькә җиткән, муниципаль берәмлек территориясендә рәсми теркәлгән һәм даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән гамәлдәге законнар нигезендә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләреннән төзелә.

8.2. Иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый (түләүсез) нигездә алып баралар.

8.3. Иҗтимагый совет әгъзаларын милли, дини, төбәк яки фирка принцибы буенча берләштерү рөхсәт ителми.

8.4. Иҗтимагый совет әгъзалары үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда коммерцияле булмаган оешмаларның, шулай ук аларны тәкъдим иткән хезмәт коллективларының карарлары белән бәйле түгел.

8.5. Иҗтимагый совет әгъзасы булып түбәндәге затлар була алмый:

1) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар,Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары, шулай ук «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башка затлар;

2) суд тарафыннан хокукый сәләтсез яки чикләнгән сәләтле дип танылган кешеләр;

3) бетмәгән яки юк ителмәгән хөкем ителүләре булган кешеләр;

4) башка дәүләтнең (башка дәүләтләрнең) гражданлыгы булган затлар, яшәүгә рөхсәте яки Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ;

5) Иҗтимагый Советта әгъзалыгы элегрәк Кодексны тупас бозу нигезендә туктатылган затлар - Иҗтимагый Совет утырышында кабул ителгән Иҗтимагый Совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе карары буенча. Бу очракта Иҗтимагый советта әгъзалыкны түбәндәге составтагы Иҗтимагый совет эшенә генә карауны тыю.

8.6. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары, әгәр Иҗтимагый совет әгъзаларының яртысыннан артыгы алар өчен тавыш биргән булса, беренче утырышта ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан сайлана. Иҗтимагый совет рәисен һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

8.7. Иҗтимагый совет составына үз вәкилен тәкъдим итәргә теләк белдергән оешма, массакүләм мәгълүмат чараларында Иҗтимагый советның яңа составы формалашуы турында мәгълүмати хәбәр рәсми рәвештә басылып чыккан көннән алып күрсәтелгән срокка муниципаль берәмлек башлыгына яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына (депутатлар Советы) яки гамәлдәге составның Иҗтимагый Советына үз вәкилен Иҗтимагый советның яңа составына кертү турында гариза җибәрә, ул оешманың җитәкче коллегиаль органы карары белән рәсмиләштерелә, әлеге орган закон нигезендә яки әлеге оешма Уставына ярашлы рәвештә тиешле вәкаләтләргә ия булган, ә коллегиаль орган булмаганда закон нигезендә яки әлеге оешма Уставына ярашлы рәвештә әлеге оешма исеменнән чыгыш ясау хокукына ия булган башка орган карары буенча түбәндәге документларны җибәрә:

1) әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча Иҗтимагый совет составына үз вәкилен кертү турында анкета;

2) анкетага оешманың дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе, оешма уставының күчермәсе һәм Иҗтимагый совет составына кандидат тәкъдим итү турында карар кабул иткән органның вәкаләтләрен раслаучы башка документлар, Иҗтимагый совет составына кандидат тәкъдим итү турында орган оешмасы уставына ярашлы рәвештә вәкаләтле карар теркәлә;

3) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык;

4) 3х4 кә фото;

5) паспорт күчермәсе.

8.8. Әгәр документларны кабул итүнең билгеләнгән чоры тәмамлангач, Иҗтимагый совет әгъзалыгына кандидатлар саны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан азрак булып чыкса, муниципаль берәмлек башлыгы Иҗтимагый совет әгъзалыгына кандидатларны өстәмә рәвештә тәкъдим итү максатыннан күрсәтелгән чорны 15 көннән дә артмаган срокка озайта.

Документларны кабул итү тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Иҗтимагый советны формалаштыру процедурасы гамәлгә ашырыла.

8.9. Иҗтимагый совет әгъзаларын 30 календарь көн эчендә раслау турында карарны муниципаль берәмлек башлыгы кабул итә һәм тиешле карарны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар советы) чираттагы сессиядә кабул итә.

8.10. Иҗтимагый совет әгъзаларының калган өчтән бер өлеше муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы) тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә артык булмаган вакыт эчендә расланган Иҗтимагый совет әгъзалары карары белән раслана.

8.11. Иҗтимагый совет әгъзаларының калган өчтән бер өлешен раслау тәртибе Иҗтимагый совет Регламентында беркетелә.

8.12. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Иҗтимагый советның яңа әгъзасын раслауны Иҗтимагый совет әгъзасын раслаган орган яки муниципаль берәмлек башлыгы һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (депутатлар Советы) тарафыннан вәкаләтләре туктатылган көннән алып 30 календарь көн эчендә расланган Иҗтимагый совет әгъзалары башкара.

8.13. Иҗтимагый совет әгъзалыгына кандидат, муниципаль берәмлек башлыгына һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына язма гариза җибәреп, Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан раслауга ризалык турында гаризасын теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Бу очракта кандидат Иҗтимагый совет әгъзалыгына кандидатлар исемлегеннән төшереп калдырыла.

8.14. Иҗтимагый совет әгъзалыгына түбәндәге иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларга кандидатлар тәкъдим итәргә рөхсәт ителми:

1) коммерцияле булмаган оешмалар, гамәлдәге составның Иҗтимагый советы әгъзаларының вәкаләтләре срогы тәмамланган көнгә кадәр бер елдан да кимрәк вакыт калганда теркәлсә;

2) сәяси фиркаләр;

3) коммерцияле булмаган оешмалар, аларга "Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында" 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон

нигезендә (алга таба – «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» Федераль закон) экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашыруның рөхсәт ителмәве турында язма формада кисәтү бирелгән көннән алып бер ел дәвамында, әгәр ул суд тарафыннан законсыз дип танылмаса;

4) эшчәнлекләрен туктатып тору турындагы карар суд тарафыннан законсыз дип танылмаган булса, "Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында" 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә туктатылган коммерциягә карамаган оешмалар.

8.15. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре өч ел тәшкил итә һәм яңа состав Иҗтимагый советының беренче утырышы көненнән исәпләнә. Яңа составның Иҗтимагый советының беренче утырышы көненнән гамәлдәге составның Иҗтимагый советы әгъзаларының вәкаләтләре туктатыла.

8.16. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) аның вәкаләтләре срогы тәмамлану;

2) аның тарафыннан Иҗтимагый совет составынан чыгу турында гариза бирелү;

3) аның сәламәтлеге буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмавы, Иҗтимагый совет эшчәнлегеннән үз-үзен читләштерүе яки башка сәбәпләр аркасында;

4) аңа карата чыгарылган гаепләү карарының законлы көченә керүе;

5) аны хокукка сәләтсез яки чикләнгән сәләтле һәм законлы көченә кергән суд карары нигезендә хәбәрсез югалган дип тану;

6) аның этика нормаларын тупас бозуы Иҗтимагый совет карары буенча, утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының күпчелек тавышлары белән кабул ителгән;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;

8) Иҗтимагый совет утырышлары эшендә җитди сәбәпсез системалы (өч тапкырдан артык) катнашмау;

9) Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары йөкләмәләрен (йомышларын) җитди сәбәпләр аркасында системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) үтәмәү;

10) аны Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенен башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү;

11) аның ике гражданлык алуы;

12) муниципаль берәмлек чикләреннән даими яшәү урынына чыгу (күчүе);

13) Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет утырышында кабул ителгән Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган карары буенча этика кодексын (Иҗтимагый совет Президиумы тарафыннан эшләнгән) бозуы.

Иҗтимагый совет әгъзасы сәламәтлеге буенча эшчәнлек алып бара алмаган, судның гаепләү карарына карата законлы көченә кергән, Россия Федерациясе

гражданлыгы туктатылган очракларда Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәисе урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

## 9. Иҗтимагый Совет вәкаләтләре

9.1. Иҗтимагый советның төп вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль берәмлекнең иҗтимагый әһәмиятле муниципаль хокукый актлары проектларын һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган башка документларны карау;

2) муниципаль берәмлекнең җирле әһәмияте, муниципаль берәмлектә җирле үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хокукый көйләүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

3) җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хокукый җайга салуны камилләштерү, муниципаль берәмлек территориясендә җирле үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

4) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеше стратегиясе проектларын, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеше фаразын һәм муниципаль берәмлекнең стратегик планлаштыруның башка документларын эшләүдә һәм карауда, аларның үтәлеше турындагы хисапларны карауда катнашу;

5) муниципаль программалар, ведомство максатчан программалар һәм башка программалар проектларын эшләүдә һәм карауда катнашу;

6) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы эштә катнашу, муниципаль берәмлекнең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуның нәтиҗәлелеген бәяләү;

7) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмаларның эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру, шул исәптән:

7.1) муниципаль берәмлекнең иҗтимагый әһәмиятле муниципаль хокукый актлары проектларын карау;

7.2) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын мониторинглауда, муниципаль контрольне тормышка ашыру функцияләрен гамәлгә ашыруда, коррупциягә каршы эш алып бару барышында катнашу;

7.3) гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләренә җавапларның сыйфатын сайлап анализлауны гамәлгә ашыру;

7.4) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләрен, Россия Федерациясе Президенты Указларын һәм күрсәтмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын һәм боерыкларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Указларын һәм күрсәтмәләрен үтәү мәсьәләләрен карау, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) йөкләмәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, шулай ук «юл карталарын», стратегик планлаштыру документларын, дәүләт, муниципаль һәм башка программаларны гамәлгә ашыру;

7.5) иҗтимагый советлар эшчәнлеген мониторинглау, иҗтимагый контроль субъектлары функцияләрен үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының иҗтимагый контроль һәм Иҗтимагый советлар белән хезмәттәшлек комиссиясе вәкилләре Иҗтимагый советлар утырышларында, шулай

ук Иҗтимагый советлар вәкилләренең эш очрашуларында һәм утырышларында катнашалар;

8) гражданлык җәмгыяте һәм Кеше хокуклары институтларын үстерүгә ярдәм итү буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән хезмәттәшлек.

9.2. «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2017 елның 20 июлендәге 62–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә белән Иҗтимагый советка йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру максатларында Иҗтимагый совет хокуклы:

1) Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аерым җәмәгать вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына күрсәтелгән органнар һәм оешмалар компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча гарызнамәләр җибәрергә;

2) муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый актларына, муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый актлары проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

3) муниципаль берәмлекнең икътисади һәм социаль үсешенең иң мөһим мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;

4) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерцияле булмаган оешма вәкилләрен, аларның компетенциясенә керген мәсьәләләрне тикшергәндә, Иҗтимагый совет утырышларына чакырырга;

5) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне караганда утырышларда, коллегияләрдә, консультатив киңәшмәләрдә, иҗтимагый советларда, комиссияләрдә катнашу өчен үз әгъзаларын (вәкилләрен) җибәрергә;

6) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законның 3 бүлегендә, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»2017 елның 20 июлендәге 62–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсендә каралган формаларда җәмәгать контролен гамәлгә ашырырга;

7) җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны оештыручылар, инициаторлар сыйфатында чыгыш ясау, шулай ук үткәрелә торган чараларда катнашу;

8) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башка органнарыннан һәм оешмаларыннан җәмәгать контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратырга, дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүмат, шәхси мәгълүмат

һәм федераль законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматтан гайре;

9) җәмәгать контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча йомгаклау документын әзерләргә һәм аны җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларга, федераль законнарга ярашлы рәвештә аерым җәмәгать вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башка органнарына һәм оешмаларына һәм гаммәви мәгълүмат чараларына карауга җибәрергә;

10) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга;

11) иҗтимагый мөһим проблемалар буенча форумнар, тыңлаулар, «түгәрәк өстәлләр» һәм башка чаралар үткәрергә;

12) Иҗтимагый совет эшчәнлегенә Россия Федерациясе гражданнарын, вәкилләре Иҗтимагый совет составына кермәгән оешмаларны, турыдан-туры һәм (яки) аларның фикерләрен, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен, белгеч-экспертларын, фәнни һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә;

13) Иҗтимагый совет утырышларында карала торган мәсьәләләрне яктырту буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итәргә.

9.3. Иҗтимагый совет җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда бурычлы:

1) иҗтимагый контроль турында Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә;

2) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән бәйле федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3) федераль законнарга ярашлы рәвештә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының, муниципаль оешмаларның, башка муниципаль берәмлек органнарының һәм оешмаларының законлы эшчәнлегенә киртәләр тудырмаска;

4) җәмәгатьчелек контроле вакытында алынган мәгълүматның конфиденциальлеген саклау, әгәр аның таралуы федераль законнар белән чикләнгән булса;

5) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 21.07.2014 № 212-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җәмәгать контролен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»2017 елның 20 июлендәге 62–ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру буенча үз эшчәнлеге һәм контроль нәтиҗәләре турында мәгълүматны халыкка җиткерергә;

6) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка бурычларны үтәргә.

9.4. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә (алга таба-«Интернет» челтәре) «Татарстан Республикасында иҗтимагый контрольне гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында»2017 елның 20 июлендәге 62 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 маддәсендәге 2 пункты нигезендә муниципаль берәмлек хакимиятенең рәсми сайтында урнаштырыла.

## 10. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

10.1. Иҗтимагый совет әгъза хокуклы:

1) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ. б.) катнашырга, федераль законнар нигезендә дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматны, шәхси мәгълүматны һәм чикләнгән керү мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматны куллану белән бәйле рәвештә керү чикләнгән чаралардан гайре;

2) инициатив тәртиптә Иҗтимагый советка аналитик язмалар, докладлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;

3) Иҗтимагый совет рәисе аша эш планына һәм утырышлар үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

4) көн тәртибе мәсьәләләрен карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырылган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

10.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы (тиеш):

1) Иҗтимагый совет рәисе биргән йөкләмәләрне (кушканнарны, йомышларны) үтәргә;

2) Иҗтимагый советның әлеге Нигезләмәдәдә каралган эш тәртибен белүергә һәм үтәргә;

3) Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

4) аңа йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан төзелгән эксперт, эшче төркемнәр, комиссияләр, башка эшче органнар эшендә катнашырга.

## 11. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру

11.1. Яңа составның Иҗтимагый советы үзенең беренче утырышына Иҗтимагый советның хокукый составы формалашканнан (булдырылганнан) соң 30 көннән дә соңга калмыйча җыела.

11.2. Яңа составтагы Иҗтимагый советның беренче утырышын Иҗтимагый совет рәисе сайланганчы элекке Иҗтимагый советның иң өлкән әгъзасы ача һәм алып бара.

11.3. Иҗтимагый советның беренче утырышы көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр кертелә һәм карала:

-Иҗтимагый советның рәисен, урынбасарын һәм сәркатибен сайлау турында;

- Иҗтимагый совет әгъзаларын раслау турында;

- яңа составның Иҗтимагый советы эшенең төп юнәлешләре турында;

- Иҗтимагый совет Регламентына тәкъдимнәр һәм үзгәрешләр кертү яки раслау турында;

11.4. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп формалары булып Иҗтимагый Совет комиссияләре (эшче төркемнәр) утырышлары, форумнар, тыңлаулар, «түгәрәк өстәлләр» һәм иҗтимагый мөһим мәсьәләләр буенча башка чаралар тора.

11.5. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк үткәрелми. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11.6. Җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалар, федераль законнарга ярашлы рәвештә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка муниципаль

органнар һәм оешмалар ул җибәргән карарларны, җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документларын карыйлар һәм Иҗтимагый советка нигезле җавапларны аларны алганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, ә кичектергесез очракларда кичекмәстән җибәрәләр.

11.7. Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына һәм законнарда билгеләнгән очракларда норматив хокукый актларга Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары инициативасы буенча үткәрелә.

11.8. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга тиеш. Иҗтимагый совет әгъзалары үз вәкаләтләрен башка кешеләргә тапшырырга, шулай ук тавыш бирү хокукын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына тапшырырга хаклы түгел.

11.9. Иҗтимагый советның даими эшләүче эшче органы булып Президиум тора. Президиумны Иҗтимагый совет төзи. Иҗтимагый совет президиумы составына рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип, комиссияләр һәм (яки) эшче төркемнәр рәисләре керә.

11.10. Иҗтимагый совет утырышларын рәис, ә ул булмаганда рәис урынбасары үткәрә.

11.11. Иҗтимагый совет рәисе:

1) Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый советының эш планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны [illegible]

3) муниципаль берәмлекнең [illegible] берләшмәләрдә һәм оешмаларда иҗтимагый советны тәкъдим итә;

4) Иҗтимагый советның җәмәгать контролен гамәлгә ашыруда катнашу нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый совет тарафыннан әзерләнгән йомгаклау документларына, утырыш беркетмәләренә, Иҗтимагый советның тәкъдимнәренә һәм башка документларына кул куя;

5) Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;

6) Иҗтимагый совет эшчәнлегенең аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

7) Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

11.12. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

1) рәис рәсми рәвештә булмаган вакытта Иҗтимагый совет рәисе вазыйфаларын башкара;

2) Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

3) Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

11.13. Иҗтимагый Советның җаваплы сәркатибе:

1) утырышларга һәм карар проектларына материаллар әзерләүне оештыра;

2) Иҗтимагый совет әгъзаларына үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

3) муниципаль берәмлекнең Иҗтимагый советы һәм җирле үзидарә органнарының оештыру хезмәттәшлеген тәэмин итә;

4) Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

5) Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тота;

6) Иҗтимагый совет утырышы көн тәртибе проектын, шулай ук утырышка чакырылган затлар исемлеген төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслау өчен тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет сәркатибе булмаган очракта, аның бурычларын Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының берсе башкара.

Иҗтимагый Совет комиссияләре рәисләре Иҗтимагый совет утырышында сайлана.

11.14. Иҗтимагый советның чираттан тыш утырышы Иҗтимагый совет рәисе карары буенча яки Иҗтимагый совет әгъзаларының билгеләнгән санының өчтән бер өлеше инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.

11.15. Иҗтимагый совет эшендә муниципаль берәмлек башлыгы һәм аның урынбасарлары, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе һәм аның урынбасарлары, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органнары (депутатлар советы), җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты хезмәткәрләре катнаша ала.

11.16. Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге үрнәк Нигезләмәнең 11.7 пунктында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын карау муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Иҗтимагый советка җибәрелгән көннән алып ун календарь көн эчендә башкарыла.

Норматив хокукый актлар (норматив хокукый актларның) проектларының Иҗтимагый советы бәяләмәсен бирү максатыннан тавыш бирүне Иҗтимагый совет рәисе, ә ул булмаганда, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертеп, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларыннан сораштыру формасында читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрергә мөмкин. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка элемтә аша документлар алмашу юлы белән үткәрелергә мөмкин, ул тапшырылган һәм кабул ителгән хәбәрләрнең тәңгәллеген һәм аларның документаль раслауын тәэмин итә. Читтән торып тавыш бирү үткәрелгән очракта, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителгән көн тәртибе, Иҗтимагый советның бәяләмәсен уздыруга кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча бирергә тиешле норматив хокукый акт (норматив хокукый акт) проекты җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары, кирәк булганда, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарыннан карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча өстәмә материаллар һәм мәгълүмат сорыйлар һәм алалар.

Иҗтимагый совет карарлары Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тәкъдим ителгән

карарның "яклап" һәм "каршы" тавышлары саны тигез булганда, Иҗтимагый совет рәисе тавышы хәл итүче дип санала.

11.17. Иҗтимагый совет утырышларында сорауларны тыңлауга һәм фикер алышуга әзерләү өчен Иҗтимагый совет әгъзалары эшче, эксперт төркемнәренә һәм башка эшче органнарга берләшә алалар, Иҗтимагый совет составына кермәгән белгечләрне материалларны әзерләүгә Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешү буенча җәлеп итә алалар.

11.18. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүмат һәм бәяләмәләр бирү өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзасы булмаган гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре чакыру буенча утырышларда катнаша ала.

11.19. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына Иҗтимагый совет утырышы билгеләнгән көнгә кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак тәкъдим итү Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары белән килештерелә.

11.20. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатларга, бурычларга, вәкаләтләргә ярашлы кабул ителгән карарлары тәкъдим итү характерында була һәм кызыксынган затларга утырыш беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Иҗтимагый совет карары буенча башка ысул белән җиткерелә.

11.21. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырыла.

## 12. Иҗтимагый советның үз эшчәнлеге турында ел саен бирелә торган хисабы

12.1. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеге турында ел саен хисап әзерли (алга таба хисап).

12.2. Эш нәтиҗәләре буенча хисап муниципаль берәмлекнең Иҗтимагый советы утырышында тыңлана.

12.3. Хисап муниципаль берәмлек хакимиятенең рәсми сайтларында Интернет челтәрендә урнаштырыла.

12.4. Хисап муниципаль берәмлек башлыгына, муниципаль берәмлек Прокуратурасына һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына җибәрелә.

12.5. Хисапта булган тәкъдимнәр муниципаль берәмлекнең икътисади һәм социаль үсешен планлаштырганда, шулай ук муниципаль берәмлекнең икътисади һәм социаль үсеше буенча чараларны гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлек органнары тарафыннан исәпкә алына.

## 13. Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү

13.1. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру, хокукый, аналитик, мәгълүмати, документлар белән, финанс һәм матди-техник тәэмин итү муниципаль берәмлек администрациясе тарафыннан башкарыла.

13.2 Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек хакимиятен тотуга каралган акчалар хисабына башкарыла.

__________________районы
муниципаль берәмлегенең
Иҗтимагый советы турындагы
Нигезләмәсенә кушымта 1.

_________________________районы
муниципаль берәмлеге Иҗтимагый советы әгъзалыгына кандидатның

## АНКЕТАСЫ

Фотография өчен урын

1 ________________________________________
(фамилиясе)

________________________________________
(исеме)

________________________________________
(атасының исеме)

2 ______________ елда туган____________________________________________
( туу датасы) (туган урыны)

3 ____________________________________________________________
(фактагы тору урыны)

____________________________________________________________

4 ____________________________________________________________
(гражданлыгы)

5 ____________________________________________________________
(паспорт яки аны алыштыручы документ: документның төре, серия, номер, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

____________________________________________________________

6. Белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме турында мәгълүмат

| Тәмамлаган елы | Белем бирү (фәнни) оешмасының исеме | Әзерлек юнәлеше яисә белгечлек, квалификация, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

1. Соңгы 10 елда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар

| Керү һәм китү елы | Эшләгән урыны | Вазыйфасының аталышы (исеме) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

6. Иҗтимагый эшчәнлек тәҗрибәсе турында мәгълүматлар

| Чор | Иҗтимагый эшчәнлек төре һәм/яки вазыйфа, билгән позициясе | Искәрмә |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

6. Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары каршындагы эксперт һәм киңәшмә органнарында, эшче төркемнәрдә катнашу турында мәгълүматлар

| Башлану һәм тәмамлану елы | Органның (төркемнең) аталышы | Искәрмә |
|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

6. ______________________________________________
(бүләкләр, кызыксындырулар, шулай ук кандидат үзе турында хәбәр итәргә теләгән өстәмә мәгълүмат)______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

7. Минем кандидатураны килештерелгән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый совет әгъзасына куела торган таләпләргә туры килүне раслыйм һәм Иҗтимагый совет составына керергә ризалыгымны белдерәм ______________________.

(имза)

8. РАСЛЫЙМ:

1) Минем тарафтан бирелгән мәгълүматның дөреслеген ____________________
(имза)

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмим, шулай ук даими түләүле нигездә эшләүче федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәдәге депутат булып тормыйм ____________________

(имза)

3) юкка чыгарылмаган яисә бетмәгән хөкем ителүе булмау ____________________
(имза)

4) миңа карата судның хокукый сәләтсез яки чикләнгән сәләтле дип тану турында карары булмау ____________________
(имза)

5) мәнфәгатьләр низагы булмау ____________________
(имза)

«____»____________ ________ел ____________________ ____________________
( тутыру датасы) (имза) (расшифровкасы)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Иҗтимагый советы турындагы
Нигезләмәгә
кушымта 2

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТНЫ ЭШКӘРТҮГӘ
РИЗАЛЫК

____________________ «____»__________, 20 ___ел

Мин,______________________________________________________________________
паспорт серия_______ номер_______________, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән
__________________________________________________________________
бүлекчәнең кодлы___________, түбәндәге адрес буенча торучы:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенә ярашлы рәвештә, вәкаләтле вазыйфаи затларга ризалык бирәм

_________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________,
(Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы аталышы)
түбәндәге адрес буенча теркәлгән:___________________________________________
_____________________________________________________________________________________,

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый Советына түбәндәге шәхси һәм биометрик мәгълүматларны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советын формалаштыру максатында эшкәртүгә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, елы, ае, туу датасы һәм урыны, гражданлыгы, адресы, фотографияләре, телефон номеры, белеме, һөнәре, хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эшләр, дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр, аерымлык билгеләре, җәмәгать өлкәсендәге эш турында мәгълүмат, паспорт һәм үзе турында хәбәр иткән башка өстәмә мәгълүматларны шәхси мәгълүматлар белән автоматлаштыру чараларын кулланып яки андый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәлләрне (операцияләр) җыелмасы) (җыйнауны, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), алу, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, керү), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блоклау, бетерү, юк итүне кертеп.

Мин шәхси мәгълүматларыма керү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы, Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы тарафыннан кандидатлар исемлеген формалаштыру һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Иҗтимагый советы составына кертү өчен шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен вәкаләтле затка бирелачәгенә ризалык бирәм.

Мин таныштырылдым түбәндәгеләр белән:
1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүгә кул куелган көннән алып Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советында әгъза булу срогы дәвамында гамәлдә;
2) шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык ирекле формада язма гариза нигезендә кире кайтарылырга мөмкин;

3) Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын кире алган очракта, «Шәхси мәгълүматлар турында»2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсенең 1 өлешендәге, 10 маддәсенең 2 өлешендәге һәм 11 маддәсенең 2 өлешендәге 2-11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда, шәхси мәгълүматларны ризалыксыз эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

4) Иҗтимагый совет составыннан чыкканнан соң, шәхси мәгълүматлар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган документларны саклау срогы дәвамында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органында саклана.

____________________ __________________ ____________________

(дата) (имза) (расшифровкасы)